**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.10.2021 Казан шәһәре № 383

Татарстан Республика Спорт министрлыгының 2019 елның 18 ноябреннән «Республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең региональ иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (региональ бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 364 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә

**боерам:**

1. Татарстан Республика Спорт министрлыгының 2019 елның 18 ноябреннән «Республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 364 номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Боерык атамасын түбәндәге редакциядә бирергә: «Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә)

дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

Боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә: «Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлә торган административ регламентын расларга».

2. Татарстан Республика Спорт министрлыгының 2019 елның 18 ноябреннән 364 номерлы боерыгы белән расланган Республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 30 октябреннән 328 номерлы, 2021 елның 22 июненнән 235 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа редакциядә биреп, үзгәрешләр кертергә (теркәлә).

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт
Министрлыгының 2019 елның
18 ноябреннән 364 номерлы
боерыгы белән раслана
(Татарстан Республикасы Спорт
министрлыгының 2021 елның
8 октябреннән 383 номерлы
боерыгы редакциясендә)

Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының административ процедурадары һәм административ гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: юридик затлар – бөтенроссия спорт федерацияләренең төбәк иҗтимагый оешмалары яки структур бүлекчәләре (төбәк бүлекчәләре) (алга таба – гариза бирүче).

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу өчен вәкаләтләре закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе белән расланган вәкил аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләре – югары казанышлар спортын үстерү бүлеге хезмәткәрләре (алга таба – бүлекнең вазыйфаи затлары) башкара.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 нче йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:00 дан 12:45 кә кадәр.

Гаризалар кабул итү тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «Божра» тукталышына кадәр:

- 1, 91, 35а, 37, 29, 90, 71, 47 нче номерлы автобуслар;
- 2, 7, 17, 6, 8, 12 нче номерлы троллейбуслар белән,

- метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

Бинага үткәрү кәгазе һәм (яки) шәхесне раслый торган документ буенча керергә мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: (http://minsport.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http://gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

3) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры) урнаштырыла.

1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү һәм үтәлү барышы мәсьәләләре буенча консультация бирү:

1) Бердәм порталның, Республика порталының интерактив формасында;

2) Министрлыкта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән Министрлыкның югары казанышлар спорты бүлегенә (алга таба – Бүлек) яки 8 (843) 221-81-50 телефоны буенча;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә – почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрындагы белешмәләр нигезендә Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүмат алу мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән аны урнаштыру гариза бирүченең техник чараларына программа белән тәэмин итү хокукына ия булган лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә, гариза бирүчедән түләү, теркәлү яки авторизацияләү яки шәхси мәгълүматлар бирүне күз алдында тоткан программа тәэминатын кулланмыйча гына гамәлгә ашырыла.

1.3.5. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, кергән мөрәҗәгать нигезендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

1) Министрлыкның урнашу урыны турында (адрес, эш тәртибе, белешмә өчен телефоннары);

2) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, гариза бирү юллары һәм сроклары турында;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча рәсми сайтта мәгълүмат урнаштыру урыны турында;

7) Министрлык вазыйфаи затларының гамәлләренә яки гамәл кылмауларына шикаять бирү тәртибе турында.

Язма мөрәҗәгать буенча Бүлек хезмәткәрләре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекләп аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать ителгән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3.6. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә өчен телефоннары, эш тәртибе, рәсми сайт адресы, шулай ук электрон почтасы турындагы мәгълүмат Министрлыкның мәгълүмати-аналитик тәэмин итү һәм халыкара эшчәнлек бүлеге белгече тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика порталында һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрында урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат үз эченә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте турында мәгълүматларны ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрында урнаштырылган.

Регламентның гамәлдәге редакциясендәге тексты Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрында, Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Аккредитация буенча орган тарафыннан дәүләт аккредитациясе түбәндәге очракларда игълан ителә:

а) иҗтимагый оешма спорт төрләренең бөтенроссия реестрының (алга таба – СТБР) беренче бүлегенә – спортның танылган төрләре (хәрби-гамәли, хезмәт-гамәли, шулай ук гомумироссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләреннән тыш), СТБР икенче бүлегенә – гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре, СТБР өченче бүлегенә – әлеге спорт төре буенча региональ спорт федерациясе булмаганда, милли спорт төрләрен үз эченә алган спорт төрләре буенча дәүләт аккредитациясе игълан итү өчен аккредитация буенча органга мөрәҗәгать иткәндә;

б) әлеге спорт төре буенча республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе гамәлдә булу вакыты тәмамланганда;

в) әлеге спорт төре буенча төбәк спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу вакыты тәмамлану көненә кадәр 4 айдан да кимрәк вакыт эчендә төбәк спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясен игълан

итү өчен аккредитация буенча органга мөрәҗәгать иткәндә.

1.6. Спортның бер төре буенча Татарстан Республикасы территориясендә Министрлык бары тик бер төбәк спорт федерациясен генә аккредитацияләргә тиеш.

1.7. Төбәк спорт федерацияләре дәүләт аккредитациясе дүрт елдан да артык вакытка гамәлгә ашырылмый.

1.8. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре файдаланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ) таләпләренә җавап бирә торган һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр, шул исәптән электрон формада да, күрсәтүне оештыруга вәкаләтле, дәүләт яки муниципаль учреждениесенең оештыру-хокукый формасында төзелгән оешмасы;

МФҮ нең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 нче пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган МФҮнең территориаль үзенә аерым структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең шулар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата).

ИАБС – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау (210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 нче маддәсенең 1 нче пункты) дигәнне аңлата.

Гаризаның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында бирелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе.

2.2. Башкарма хакимият органы атамасы.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү.

1. Региональ спорт федерацияләре статусын бирү өчен бөтенроссия спорт федерациясенең төбәк иҗтимагый оешмаларына яки структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә) дәүләт аккредитациясе (алга таба – дәүләт аккредитациясе) турында Министрлык боерыгы.

2. Региональ спорт федерациясе статусы барлыгын раслый торган дәүләт аккредитациясе турында документ бирү.

3. Иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында карар.

4. Региональ спорт федерациясе статусы барлыгын раслый торган дәүләт аккредитациясе турында документ дубликатын бирү.

Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша биргән очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт аккредитациясе турында карар (әлеге Регламентка 7 нче кушымта) яисә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 8 нче кушымта) шәхси кабинетка җибәрелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып; әгәр Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (юллау) вакыты

Дәүләт аккредитациясе әлеге Регламентның 1.5 пунктында каралган шартлар килеп туган көннән 10 эш көне эчендә игълан ителә.

Дәүләт аккредитациясе турында гариза бирүче тарафыннан гариза, мәгълүматлар һәм документлар бирү вакыты дәүләт аккредитациясен игълан итү турында документка кул куелган көннән соң 20 эш көненнән кимрәк һәм 40 эш көненнән артыграк була алмый.

Иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе турында яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында карар аккредитация буенча орган җитәкчесе тарафыннан иҗтимагый оешманың гариза, әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган мәгълүматлар һәм документларны бирү вакыты узган көннән соң 2 айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт аккредитациясе яисә дәүләт аккредитациясеннән баш тарту турында хәбәрнамә – документка кул куелган көннән соң 5 эш көне эчендә тапшырыла һәм / яки Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү – төбәк иҗтимагый оешмасы аккредитация турында документ биргән өчен дәүләт пошлинасын түләгәннән һәм Министрлыкка дәүләт пошлинасын түләүне раслый торган документны тапшырганнан соң 15 эш көне эчендә.

Дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү (таныклыкны югалту яки бозу очрагында) – Министрлыкка дәүләт

аккредитациясен раслый торган документ дубликатын бирү турында гаризаны биргән көннән соң 30 эш көне эчендә.

Дәүләт аккредитациясен раслый торган документны яңадан рәсмиләштерү (яңасын бирү) (төбәк спорт федерациясенең атамасы һәм/яки аның урнашкан урыны үзгәргән очракта) – дәүләт аккредитациясе турында документка тиешле үзгәрешләр кертү турында документны имзалаган көннән соң 30 эш көне эчендә.

Мөрәҗәгать итүчегә электрон документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, Гариза бирүче тарафыннан аларны алу, шул исәптән электрон формада да, ысуллары, аларны бирү тәртибе

1. Дәүләт аккредитациясен алу өчен:

а) региональ иҗтимагый оешмасының дәүләт аккредитациясе турында гаризасы (2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча);

б) региональ иҗтимагый оешманың Уставы күчермәләре (бер күчермә нотариаль тәртиптә расланган булырга тиеш) һәм, региональ иҗтимагый оешма гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе (региональ бүлеге) булып торган очракта, гомумроссия спорт федерациясенең даими эшли торган җитәкче органының региональ иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясе бүлекчәсе булып торуы турында, төбәк иҗтимагый оешмасының урнашкан урыны һәм җитәкче органнары турында мәгълүматларны күрсәтеп, белдерү кәгазе;

в) региональ иҗтимагый оешма әгъзалары булып торган затлар исемлеге (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

г) региональ иҗтимагый оешма җитәкче органнарының персональ (шәхси) составы турында мәгълүматлар (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);

д) иҗтимагый оешма төзү, аның уставын раслау һәм җитәкче органнар һәм тикшерү-ревизия органын формалаштыру турында оештыру съезды (конференциясе) яки гомуми җыелыш беркетмәсенең;

коммерциячел булмаган оешманың дәүләт теркәве турында таныклыгының региональ иҗтимагый оешма раслаган күчермәләре;

е) гомумроссия спорт федерациясенең иҗтимагый оешмага – СТБР икенче бүлегенә кертелгән спорт төрләре өчен – гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре һәм СТБР өченче бүлегенә – милли спорт төрләре (әлеге спорт төре буенча гомумроссия спорт федерациясе булганда) дәүләт аккредитациясенә язмача ризалык кәгазе;

ж) иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясендә әгъзалыгын раслый торган документ күчермәсе (әлеге спорт төре буенча гомумроссия спорт федерациясе булганда), әлеге пунктта каралган мәгълүматлар һәм документларны гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе (региональ бүлеге) тәкъдим итү очракларыннан тыш;

з) үсешен иҗтимагый оешма тормышка ашыра торган спорт төре буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы составына кертү өчен спортчыларны сайлап алуны тәртипкә сала торган документ проекты;

и) 329-ФЗ номерлы Федераль законның 161 маддәсе 2 өлешендәге 5нче пункт буенча эшләнгән Татарстан Республикасында тиешле спорт төрен үстерү программасы (алга таба – үсеш программасы) проекты – дәүләт аккредитациясе өчен гариза, мәгълүматлар һәм документларны беренче тапкыр тапшыра торган иҗтимагый оешмалар өчен яки дәүләт акредитациясе уздыру көненә спорт төре (төрләрен) үстерү программасын тормышка ашыру вакыты чыга торган иҗтимагый оешмалар өчен;

узган вакыт аралыгында тормышка ашырылган чараларны исәпкә алып, аның төзәтмәләр проекты белән үстерү программасы күчермәсе – дәүләт аккредитациясе уздыру вакытына үстерү программасын тормышка ашыруның вакыты чыкмаган региональ иҗтимагый оешмалар өчен;

к) иҗтимагый оешма эшчәнлеген финанслау чыганаклары, уздырылган төп чаралар, Татарстан Республикасы җыелма спорт командасының иҗтимагый оешма үсешен тормышка ашыра торган спорт төре буенча Россия чемпионатларында һәм беренчелекләрендә чыгыш ясау нәтиҗәләре турында белешмә;

л) иҗтимагый оешма уздырган кимендә 3 спорт ярышының беркетмәләре күчермәләре;

м) мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ (Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

н) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ.

«б» – «ж» пунктчаларында каралган мәгълүмат һәм документлар кәгазьдә ике данәдә, шулай ук бер данә электрон формада тапшырыла.

2. Дәүләт аккредитациясе турында документ дубликатын бирү өчен:

а) дәүләт аккредитациясе турында документ дубликатын бирү турында гариза;

б) шәхесне раслаучы документ (Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта кирәк түгел);

в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ.

3. Дәүләт аккредитациясе турында документны яңадан рәсмиләштерү (яңаны бирү) өчен:

а) дәүләт аккредитациясе турында документны яңадан рәсмиләштерү турында гариза;

б) устав күчермәсе;

в) коммерциячел булмаган оешмага дәүләт теркәве үткәрү турында таныклык күчермәсе;

г) дәүләт аккредитациясе турында элек бирелгән документ;

д) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ (Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта кирәк түгел);

е) мөрәҗәгать итүче вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ.

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (юлланырга) мөмкин:

1) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада. Республика порталы, Бердәм портал аша җибәрелгәндә, гариза гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана;
2) Министрлыкка шәхсән яки почта аша кәгазьдә. Почта элемтәсе аша юлланганда гариза һәм теркәлә торган документлар билгеләнгән тәртиптә раслана.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ИАБС да теркәлү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын расларга кирәк.

Электрон документ (документның электрон образы) мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның, шул исәптән нотариусларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар образлары), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (документларның электрон образлары) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларда булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк һәм гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче аларны, шул исәптән электрон формада да алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1. Гариза һәм документларны тапшыру көненә кадәр бер айдан артыграк булмаган вакыт эчендә бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе).

2. Дәүләт аккредитациясе турында документ бирү өчен дәүләт пошлинасын түләүне дәлилли торган документ (Федераль Казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе).

3. Россия Федерациясе гражданы паспортының чынлыгы турында мәгълүматлар (Россия ЭЭМ).

4. Нотариаль ышанычнамә турында белешмәләр (Федераль нотариаль палата).

Күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры, шул исәптән мөмкинлек булганда – электрон рәвештә дә алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче 1-2 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) гариза биргәндә, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга

вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган электрон документлар рәвешендә бирергә хокуклы.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны бирмәве гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокукы булган документларны алу юллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнә.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган документ һәм мәгълүматларны бирү һәм гамәлләрне гамәлгә ашыру;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсе 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне көйли торган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив актлары нигезендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган  дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалар карамагында булган, шул исәптән  дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен гариза бирүченең түләү кертүен дәлилли торган документлар һәм мәгълүматларны бирү;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыру.

электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә элек расланган документлар һәм мәгълүматны кәгазьдә бирү, әгәр мондый документларга билгеләр кую яки аларны алу дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури шарт булып торган һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

1) Иҗтимагый оешма тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килми торган гаризалар һәм/яки мәгълүматлар һәм/яки документлар тапшыру.

2) Иҗтимагый оешманың, әлеге Регламентның 2.4 пунктында билгеләнгән срокны бозып, гаризалар һәм/яки мәгълүматлар һәм/яки документлар тапшыруы.

3) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган, текстта төзәтүләр булу.

4) Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар булу.

5) Тапшырылган документларның дәүләт хезмәте өчен мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалтуы (күрсәтелгән зат тарафыннан дәүләт хезмәте

күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ).

6) Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада билгеләнгән таләпләрне бозып бирү.

7) Гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында мәҗбүри кырларны дөрес (ялган, тулы түгел яисә дөрес тутырылмаган) тутырмау.

8) Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру.

9) Хезмәт күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага бирелгән.

10) 2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартлары үтәлмәү.

Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр исемлеге тулы бирелгән.

Дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетына дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка документлар Бердәм порталда, Республика порталында басылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте алу өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр билгеләнмәгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

1. Иҗтимагый оешма тапшырган әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган гариза, мәгълүматлар һәм документларда дөрес булмаган мәгълүмат булуы.

2. Иҗтимагый оешманың 329-ФЗ номерлы Федераль законы 13 маддәсенең 8 өлешендәге региональ спорт федерацияләренә куелган таләпләргә туры килмәве.

3. Региональ спорт федерациясе тарафыннан дәүләт аккредитациясе юридик көчен туктату өчен сәбәп булып торган бозуларны региональ иҗтимагый оешманың бетермәве (дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы элегрәк туктатылган региональ иҗтимагый оешманың әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган белешмәләр һәм документлар, гариза бирү очрагында).

3. Региональ спорт федерациясе тарафыннан дәүләт аккредитациясе юридик көчен туктату өчен сәбәп булып торган бозуларны иҗтимагый оешманың юкка чыгармавы (дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы элегрәк туктатылган иҗтимагый оешманың әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган белешмәләр һәм документлар, гариза бирү очрагында).

Иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту очрагында андый оешма, кире кагу өчен нигез булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң, Министрлыкка дәүләт аккредитациясен игълан итү өчен кабат мөрәҗәгать итә ала, әмма оешмага дәүләт аккредитациясеннән баш тарту турында карар кабул иткән көннән соң өч айдан да иртәрәк түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында басылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте алу өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр

Дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү региональ спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү өчен 5 000 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң тормышка ашырыла.

Дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү өчен 350 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң тормышка ашырыла.

Республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе узу турында документ (таныклык) һәм дәүләт аккредитациясен узуны дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү өчен дәүләт пошлинасы түләү өчен реквизитлар:
ТР буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ш/сч 04112001180)
ИНН/КПП 1655043416/165501001;
Отделение-НБ Республики Татарстан г. Казань;
р/с 40101810800000010001;
БИК 049205001;
КОД ДОХОДА 719.10807340011000.110;
ОКТМО 92701000.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр

Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган хезмәт күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм шундый хезмәт күрсәтүләрнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган хезмәт күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, соравын (запрос) теркәү вакыты һәм тәртибе.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы белдерү кәгазе ала, анда теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән була.

Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, вәкаләтле вазыйфаи зат гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән расписка бирә.

Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар тутыру өчен урыннарга, аларны тутыру үрнәкләре һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге белән мәгълүмати стендларга, шундый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата, шул исәптән федераль һәм Татарстан Республикасының инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә таләпләр

Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бинада башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларның (кресло-коляскалар һәм озатып йөрүче этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында аларга түбәндәгеләр тәэмин ителә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына комачаулыкларсыз килү өчен шартлар:

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль яки хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә күчеп йөрү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге;

транспорт чарасына утырту һәм аннан бинага керү алдыннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм кирәк булганда, хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәме белән;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның, аларның тормыш эшчәнлекләренең чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешле итеп урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт бирү;

махсус өйрәнүен раслый торган документы булганда, озатып йөрүче этне бинага кертү;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә һәм объектлардан файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан башка кирәкле ярдәм күрсәтү;

инвалидлар тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, бинаны аларның физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнүе өчен махсус спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү;

инвалидларга, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, махсуслаштырылган төркемнәрдә физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;

инвалидлар белән физик культура һәм спорт дәресләрен үткәрү өчен әзерләнгән хезмәткәрләр булу.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, реконструкция, модернизация узган объектларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара тәэсир итешүе һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау юлы белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), башкарма хакимият

органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүен алу мөмкинлегенең булуы яисә булмавы

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

бинаның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

документларны кабул итү һәм бирү алып барыла торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы;

башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган киртәләрне узуда инвалидларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы инвалидлар өчен биналардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның мәгълүмати рсурсларында, Бердәм порталда, Республика порталында тулы мәгълүмат булуы;

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1. документлар кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

2. дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3. дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Административ регламентны бозуларына нигезләнгән шикаятьләр булмау;

4. мөрәҗәгать итүче һәм вазыйфаи затның үзара тәэсир итешүе саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

- Министрлыкта дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта - бер тапкыр.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм портал, Республика порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетында, Министрлыкта алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау (запрос) составында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте КФҮтә, КФҮнең читтәге эш урыннары аша күрсәтелми.

2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) башка таләпләр

Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәткәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Бердәм портал, Республика порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә элегрәк расланган документлар һәм мәгълүмат бирергә;

3) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның үтәлү барышы турында мәгълүмат алырга;

4) электрон документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

5) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итүче шикаять бирергә.

Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт һәм муниципаль органнар, аларның вазыйфаи затлары, хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итүче шикаять бирергә.

Гариза формалаштыру, башка нинди дә булса формада гаризаны өстәмә бирү зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә мөрәҗәгать итүченең уртак гаризасын юллауны күз алдында тоткан хезмәтләрне сорап мөрәҗәгать иткәндә, берничә мөрәҗәгать итүче гаризасының бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

4) кулланучының теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән гаризаның электрон формасына зурлыкларны кабат кертү өчен хаталар килеп чыкканда һәм кире кайтканда, гаризаның электрон формасына элегрәк кертелгән зурлыкларны саклау;

5) ИАБС да һәм Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүченең мәгълүматларны кертү алдыннан Бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә гаризаның электрон формасы кырларын тутыру;

6) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

7) мөрәҗәгать итүченең элек бирелгән гаризаларына бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга – кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узу, кабул итү максатын күрсәтү, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәк булган мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү һәм аларның эзлеклелеге.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган консультация бирү;

2) дәүләт аккредитациясе үткәрү турында игълан итү өчен мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

3) региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе үткәрүне игълан итү турында боерык чыгару;

4) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

5) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы (ВЭХС) аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларга ия органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм юллау;

6) региональ иҗтимагый оешмаларга региональ спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия утырышын үткәрү, аккредитация буенча Комиссия утырышын уздыру турында беркетмә төзү;

7) региональ иҗтимагый оешмасына дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа региональ спорт федерациясе статусы бирү яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итү;

8) Россия Федерациясе Спорт министрлыгына региональ спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында мәгълүмат һәм документларны тәкъдим итү, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү (юллау);

9) дәүләт аккредитациясе үткәрү турында документның (таныклыкның) дубликатын бирү һәм яңадан рәсмиләшерү;

10) техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хата) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар комплектын тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон), шулай ук шулай ук Республика порталында, Министрлык сайтында дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе һәм вакытлары турында, шул исәптән тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка сораулар буенча консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирүне гамәлгә ашыра. Кирәк булса, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә Гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнәторган процедура Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, Гариза бирүчегә, шул исәптән гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның билгеләнгән комплектын тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүченең вәкиле кәгазьдә бастырып шәхсән, Бердәм портал, Республика порталы, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон рәвештә яисә почта аша алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә Министрлыкка тиешле спорт төре буенча төбәк иҗтимагый оешмасына дәүләт аккредитациясе уздыру турында игълан итү өчен мөрәҗәгать (алга таба – Мөрәҗәгать) юллый.

3.3.2. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Мөрәҗәгатьне терки һәм башкару өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүчедән Мөрәҗәгать кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлгән Мөрәҗәгать.

3.4. Региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе игълан итү турында боерык бастыру.

3.4.1. Мөрәҗәгать нигезендә Бүлек белгече региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе игълан итү турында боерык проекты әзерли (алга таба – Боерык), биредә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында гариза бирү вакыты билгеләп куела. Ул әлеге Боерыкка кул куелган көннән башлап 20 эш көненнән дә кимрәк һәм 40 эш көненнән артыграк булмаска тиеш.

Боерык проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелә.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.3.2 подпункты белән билгеләнгән процедуралар тәмамланганнан вакыттан алып ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерүгә юлланган Боерык проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы Боерык проектын карый һәм килештерү өчен аларны министр урынбасарына юллый.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы белән килештерелгән Боерык проекты.

3.4.3. Министр урынбасары Боерык проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.2. һәм 3.4.3. пунктчаларында билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга кул куярга юлланган Боерык проекты.

3.4.4. Министр Боерыкны имзалый һәм теркәү өчен оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юллый.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәүгә юлланган Боерык.

3.4.5. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Боерыкны терки һәм башкару өчен Бүлеккә кире кайтара.

Әлеге Регламентның 3.4.4. һәм 3.4.5. пунктчаларында билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан өч эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән Боерык.

3.4.6. Бүлек белгече Боерыкны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра, шулай ук гариза бирүчегә дәүләт аккредитациясе игълан ителү турында аңардан алынган гаризада күрсәтелгән ысул белән белдерү кәгазе юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан өч эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган Боерык.

3.5. Гариза алу һәм теркәү

3.5.1. Гариза бирүче вәкиле шәхсән кәгазьдә, Бердәм портал, Республика порталы, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон рәвештә яисә, почта аша тапшырылу турында хәбәр кәгазле заказлы хат белән, әлеге Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гаризаны Бүлеккә тапшыра (юллый).

